Газета МБОУ «АСОШ №2»

# Пульс школы

# Мәктәп пульсы

махсус
чыгарылыш
2022 ел

## *Юбилееӊ котлы булсын, кадерле мәктәбем!*



Син балкыйсыӊ һәркем
күӊелендә
И, кадерле, газиз мәктәбем!
Күпме сабый күӊелен житә
яктыртырга,
Син кабызган утның яктысы.
Нурга күмсен иде гомереӊне
Безнеӊ гомернеӊ дә балкышы.

..90 ел ул - кыска вакыт түгел,
Шатлыкларга күмгән еллар ул.
Авыр хезмәт нәтиҗәсе аша,
Уӊышларга илткән юллар ул..
Мәктәбем, дип сиӊа баш иябез,
Безнеӊ белән бул гел янәшә.
Дан-шөһрәткә, хөрмәткә
төренеп,
Мәӊге яшә, мәктәбем, яшьнә!

**Юбилееӊ мөбәрәк, киләчәгеӊ якты, укучыларыӊ ышанычлы булсын, кадерле мәктәбем!**

### Бу санда:


- Тарих эзләреннән...
- Өйрәтәләр мәктәплӘрдә
- Мөгаллимнәр эше дәвамлы булсын!
- Что такое ШУС?
- “Алтын каләм” әдәби-иҗат түгәрәге сүз ала.

# Тарих эзләреннән...

Мәктәбебез районгдагы өлкән уку йортларының берсе. Быел аңа 90 ел.

Бу бинага күченгәнгә дә быел ярты гасыр булды.

Интернационал урамындагы бер катлы агач бинада, ике классны башлангыч мәктәп буларак, Фатыйма апа Гыймранова җитәкчелегендә 1932 нче елдан эшли башлый.




1938 нче елда җидееллык татар мәктәбе итеп үзгәртелә. 14 укытучыдан һәм 285 баладан торган мәктәпнең беренче директоры Фәйзи Әухәдиев була. 1950 нче елда мәктәп Галактионов урамындагы бинага (46 нчы йорт) урнаша.




1955 нче елда татар урта гомуми белем мәктәбе була. Иң беренче чыгарылыш 20 укучыдан тора. Тора-бара укучылар саны арта, иркенрәк бина кирәк була башлый. 1972 нче елның февраль аенда Күпер урамында төзелгән өч катлы яңа уку йортында Валерий Малков җитәкчелегендә Арчаның икенче урта мәктәбе уку елын дәвам итә.





Ун ел элек мәктәпкә капиталь ремонт ясалды. Ә 90 еллык юбилеена мәктәбебез танымаслык итеп үзгәртелде, матди-техник базасы тагын да ныгыды, кабинетлар заман таләпләренә җавап бирерлек итеп җиһазландырылды. Биредә эшләүче һәркемгә уңай эш шартлары булдыру өчен директорыбыз Гөлназ Гыйниатуллина бик зур тырышлык куя. Бүгенге көндә мәктәбебездә 661 бала белем ала, һәркемнең эчке халәтен тирән тоемлый белә торган 47 укытучы хезмәт куя. Укытучыларыбыз да, үзләренең көндәлек мәшәкатьләрен бер читкә куеп, барлык уңайлыкларны булдырырга омтылалар.



Гел карап, хасиятләп, буяп-агартып торганга, яңа булып күренә мәктәбебез. Җитәкчедән башлап мөгаллимнәргә кадәр һәммәсе бик тырыш. Бер бит кәгазь дә исраф ителми, макулатура тапшырыла, аннан кергән акчаны, мәктәп яны кишәрлегендә үскән яшелчәне сатканнан кергән керем мәктәп кирәк-яракларына тотыла.

Мәктәптә һәр укытучы төрле алымнар һәм методлар кулланып шәхес тәрбияләү максатын күздә тота, аларны киләчәк тормышка әзерли. Ул балалар өчен укытучы гына түгел - киңәшче, ярдәмче, юл күрсәтүче. Авыр юлда тугры дуслар сайларга, аларны сакларга да укытучы өйрәтә. Баланы үзенең көченә ышандыру, аның барлык эшләрне булдыра алырдай шәхес икәнен күрсәтү дә укытучыга йөкләнә.

# Өйрәтәләр мәктәпләрдә

Балалардагы табигать биргән сәләтне ачу, үстерүне укытучылар үзләренең төп бурычлары санап, хезмәт куялар. Төгәл фәннәргә тартылганнары да, гуманитар фәннәргә, йә булмаса, сәнгатькә, спортка өстенлек бирүчеләрне дә байтак булганлыктан, теләге булган һәр бала өчен түгәрәкләр эшли. «Физкультура һәм спорт», «Сәхнә» түгәрәгенә йөрүчеләр, «Күңелле тәнәфес» проектында катнашучыларны да билгеләп үтәргә кирәк. Күптән түгел республикабызның Яшьләр һәм спорт министрлыгы ярдәме белән үткәрелгән «Арча-уен» дип аталган спорт-күңел ачу ярышында катнашып, мәктәп командасы икенче урынны алып кайтты.




Монысын инде күмәк спортны үстерү белән беррәттән, яшьләргә сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен бирү.

Мәктәп укучыларының казанышлары «Яшь журналистлар» түгәрәгенә йөрүчеләрнең даими күз уңында. Ун елга якын инде алар әлеге яңалыклар белән «Мәктәп пульсы» газетасы һәм сайт аша таныштырып баралар, фоторепортажлары һәм видеосюжетлары да күңелгә үтеп керерлек.

Әлеге түгәрәккә йөрүчәләр арасында журналист һөнәрен сайлаучылар да бар.



Мәктәптә эшләп килүче “Алтын каләм” әдәби-иҗат түгәрәгенә йөрүче шигыри җанлы укучылар - үз ана телебездә иҗат итеп, үзләрен нәкъ менә шул өлкәдә сынап карарга теләк белдергән балалар.



Бу уку елында оештырылган “Күңелле татар теле” түгәрәге укучыларга туган телендә аралашу мөмкинлеге генә биреп калмый, ана телебезгә карата мәхәббәт тәрбияләүгә дә өлеш кертә.




Республикакүләм "Мөстәкыйль балалар" проектында мәктәпнең "Risk" отряды да катнаша. Бу балалар сәламәт яшәү рәвешен сайлвучылар һәм үзләре артыннан башкаларны да әйдиләр. Алар ел дәвамында төрле акцияләр үткәрәләр, Арча шәһәрендәге төрле Яшьтәге халык арасында сәламәт яшәү рәвешен пропогандыйлар. Алар арасында "Кызыл лента", "Сәламәт ана- сәламәт бала" , "Елмаю бүләк ит", Сәламәт йөгерү" акцияләре үтте.

«Игенчеләр көзен уңыш җыя, укучылар – язын», дип әйтә балалар. Әмма мул уңыш алу өчен аларга ел буена тырышып укырга кирәк, хезмәтләре дәресләрдә һәм имтиханнарда алган билгеләр белән генә бәяләнми. Алары да республика мәктәпләренең уртача күрсәткеченнән түбән түгел. Һәр елны БДБны йөз баллга тапшырган укучыларыбыз булу, фән олимпиадаларында, бәйгеләрдә һәм спорт ярышларында катнашу да еллык уңышка өстәлеп тора.

Уку елы азагында сәләтле укучыларны һәм укучыларны зурлап бүләкләү матур традициягә әверелеп бара.

# Мөгаллимнәр эше дәвамлы булсын!

Мәктәптә һәр атна башында укучыларның бергә җыелып, Россия һәм Татарстан гимннары астында илебез һәм республикабыз әләмнәрен, алмашлап, яхшы укыган, теге яки бу бәйгедә, чарада катнашып, уңышка ирешкән укучылар кулына тапшыру - тагын да тырышып укырга, ватанпәрвәрләр булырга рухландыручы бер маяк.




«Барабанчылар» ансамбле районда бары бездә, «Яшь армиячеләр» отряды сафына баскан укучыларыбыз да байтак. Алар район күләмендә уза торган патриотик чараларда актив катнашалар.




Сугыш һәм тыл ветераннары белән очрашулар, «Солдатка хат» акцияләре үткәрү тәрбия чараларын төрләндерү булып тора. Соңгы вакы-




Әлеге тәрбия дәресенә сугыш чоры баласы, ветеран укытучы Рая апа Фәтхуллина һәм районның «Боевое братство – Хәрби туганлык» иҗтимагый оешмасы рәисе Сергей Баһаутдинов чакырылган иде.

...Ветераннарның чыгышларын өлкән сыйныф укучылары тын да алмый тыңлый.



Уку йортының икенче катында тарих укытучылары көче белән оештырылган музейда бүген мәктәбебезгә кагылышлы байтак мәгълүмат табып була. Укучылар һәм аларның остазлары һәр мөһим чараны «Мәктәп елъязмасы»на теркәп бара. Бүген халкыбыз нинди уй-теләкләр, борчу-сөенечләр яшәгәнен киләчәк буыннар шул елъязмадан белер. Иң кунычлысы, мәктәбебездә өлкәннәр эшен лаеклы дәвам иттерүче булырдай яшь буын үсеп килә.

Узган ел «Үсеш ноктасы» үзәге булдырылды. Химия, физика, технология, биология фәннәреннән практик эшләр өчен җиһазлар, робототехникалар кайтартылды. Сбербанкның хәйрия фонды ярдәме белән мәктәп «Киләчәккә кертем», «Шәхесне үстерүче белем бирү мохитын булдыру» программаларында катнашу хокукына ия булды. Шуңа бәйле рәвештә укучыларның махсус ял һәм иҗат мәйданчыклары булдырылган. Боларның барысы да, ахыр чиктә, уку-укыту процессында укучы белән укытучы арасында күпер булдыру, ике якны тагын да якынайта төшү өчен эшләнелә. Мондый шартларда укучы яшь буын вәкилләренең тирән белем алачакларына, киләчәктә яшь галимнәр, яңа геройлар үсеп чыгачагына һич тә шигебез юк.

90 ел элек әлеге мәктәптә укыган балалар белән бүгенге заман яшьләре арасында аерма бик зур шул. Теләгебез – илләр имин, мөгаллимнәр эше дәвамлы булсын!

# Что такое ШУС?

Аббревиатура ШУС расшифровывается как «Школьное ученическое самоуправление». Сейчас оно существует почти в каждой школе, а так же и в МБОУ «АСОШ2». Во главе ШУСа стоит президент, избираемый всеми работниками и учениками. В нашей школе глава совета контролирует деятельность сразу шести комитетов: министерство сми,образования и порядка, культуры, спорта, милосердия и ЮИД. У каждого из них есть свои обязанности.

**Президент**:
- Организовывает стратегическое планирование деятельности;
- Определяет повестку дня и председательствует на заседаниях;
- По согласованию с секретарем назначает министров;
- Оказывает помощь секретарю и министрам;
- Осуществляет контроль исполнения решений.

**Секретарь**:
- Предлагает президенту кандидатуры министров;
- Является заместителем президента, а в его отсутсвие выполняет должностные обязанности главы;
- Проводит совещание министров и осуществляет их общий контроль работы;
- Организовывает работу по согласованию деятельности министерств.

**Министерство СМИ**:
- Содействует выпуску школьной газеты;
- Отвечает за информационное обеспечение работы;
- Отвечает за своевременное изготовление печатных поздравлений;
- Курирует информационную работу в классах;

**Министерство образования и порядка**:
- Анализ успеваемости учащихся 5-11 классов, ежемесячное подведение итогов, а также публикации в средствах школьной прессы;
- Кураторство учебной работы в классах;
- Разработка плана работы министерства;

**Министерство культуры:**
- Ответственной за проведение культурно – массовой работы;
- Участвует в организации всех культурно – массовых мероприятий и просветительских мероприятий в школе;
- Разрабатывает и предлагает на рассмотрение Президенту основных культурно – массовых мероприятий на год с указанием целей и задач.

**Министерство спорта:**
- Ответствены за проведение спортивной работы;
- Участвует в организации всех спортивно – массовых мероприятий в школе;
- Организовывает в школе проведение «Дней здоровья», товарищеских встреч с учителями и учениками по различным видам спорта;

**Министерство милосердия:**
- Привлекает внимание подрастающего поколения к нравственным понятиям "доброта", "помощь", "защита";
- Организовывает помощь нуждающимся и призывают к этому людей;
- Взаимодействуют с организациями, курирующими вопросами милосердия;

**Министерство ЮИД:**

Отряд юных инспекторов движения – это творческое объединение учащихся, которые помогают школе в организации работы по профилактике детского дорожно-транспортного травматизма, а также пропагандируют правила дорожного движения.

Министры, что стоят во главе этих групп, отдают все силы на решение вопросов, касающихся их деятельности. Все эти шесть комитетов тесно связаны друг с другом. На деле разделение обязанностей лишь формально. Ребята из ШУСа всегда поддерживают друг друга и стараются сделать так,чтобы ученики нашей школы чувствовали себя, как дома.

Школьное ученическое самоуправление- это то место, где дети могут проявить себя и показать все свои способности. Это не только работа в коллективе, это-маленькая семья.




В нашей школе 11 октября учителем физики Гараевой Дилярой Ягфаровной был проведен «Атомный урок», приуроченный ко Дню работника атомной промышленности.

На «Атомном уроке» были рассмотрены инновационные разработки в атомной промышленности, энергетики будущего, развитие безуглеродных технологий. Также учащиеся познакомились с источниками энергии на Земле, их влиянием на экологию планеты и альтернативными источниками энергии.



# “Алтын каләм”әдәби-иҗат түгәрәге

### *Бездә бүген зур бәйрәм*

Бездә бүген зур бәйрәм
Бездә бүген зур бәйрәм-
Юбилей көне икән.
Мәртәбәле мәктәбемне
Котларга вакыт җиткән.
Шатланышып җыелалар
Синдә укыган балалар.
Ныклы белем биргәненә
Куанып туймый алар.
Киләчәккә нык карашлы,
Һәркайсы изге уйда.
Күпме буын тәрбияләп
Чыгардың туры юлга.

### *Җир –ананы килә саклыйсы.*

Урман-таулар, болын-кырлар аша,
Киләчәккә килә атлыйсы...
Яшь буынга насыйп булсын байлык -
Җир–ананы килә саклыйсы.
Зәңгәр күлне иңләп коенасы,
Саф һавасын килә сулыйсы...
Табигать бит нинди гүзәл дөнья -
Җир –ананы килә саклыйсы.
Табигать күк кеше гомере дә,
Үтә язы, җәе, көз, кышы...
Һәр фасылның үзенә бер яме
Җир –ананы килә саклыйсы.

**Камилә** Гарифҗанова,
10 нчы сыйныф укучысы



Арча 2 нче номерлы гомуми белем мәктәбендә эшләп килүче “Алтын каләм”әдәби-ижат түгәрә-генә шигырь укырга һәм сөйләргә яратучы, үзләрен нәкъ менә шул өлкәдә сынап караган укучылар йөри. Алар язган шигырьләрнең тема төрлелеге әлегә чикле. Әмма укучылар үз иҗатларында тарихи вакый-ганы берничек тә чагыл-дырмый кала алмадылар.

Декабрь аенда Мәктәбебез үзенең 90 еллык юбилеен билгеләп үтәргә хәзерләнә. Шушы уңайдан, түгәрәккә йөрүче балалар, үзләре иҗат иткән шигырьләрен газета укучыларыбызга тәкьдим итәләр. Иҗат юлын сайлаган һәр балага киләчәктә уңыш-лар, каләмнәрен ешрак тиб-рәтергә насыйп булсын!

“Алтын каләм”әдәби-иҗат түгәрәге җитәкчесе, **Гөлнара** Мөбәрәкшина

### *Әй, мәктәбем, белем учагым*

Әй, мәктәбем, белем учагым,
Тарихларга кереп каласың.
Җыелышып кайчан кайтсак та,
Колач җәеп каршы аласың.
90 ел ул — кыска вакыт түгел,
Уңышларга күмгән еллар ул.
Авыр хезмәт нәтиҗәсе аша,
Белем хәзинәсен биргән шул.
Укытучыга бүген баш иябез,
Укучы белән Сез гел янәшә.
Дан-шөһрәткә, хөрмәткә төренеп,
Мәңге яшә, мәктәбем, яшьнә!

### *Казаным.*

Әй, Казаным, нурлы җирем,
Матурлыклар синдәй кайда бар?
Әкияттәй Кабан күлең мәчетләрең -
Ниләр кирәк, монда бар да бар...

Әллә каян чакырып тора
Нурлар чәчеп уку йортларың.
Һәрбер кеше искә алып сөйли
Синдә булган тәүге чакларын.

Сөембикә манарасы безне
Чакырып тора әйтеп азанын.
Мәңге яшә, һаман мәңге балкы шулай,
Зур тарихлы горур Казаным!

**Зөһрә** Мусина,
10 нчы сыйныф укучысы

***Редактор*** учитель татарского языка и литературы Ибраева Р.Х.
***Дизайнер - верстальщик*** Алсу Минһаҗева
***Фотокорреспондент*** Ислам Мингазов
***Корректор*** Ранис Исмагилов
***Редколлегия*** Ислам Сафин

*Адрес: ул.Мостовая, д.15.*
*Сайт: https://edu.tatar.ru/arsk/sch2*